РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

28.08.2020 ел №291

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2014 елның 19 мартындагы 211 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законнар, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә, Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2014 елның 19 мартындагы 211 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында» (муниципаль район Советының 2019 елның 12 апрелендәге 215 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.4 пунктының 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлады, дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә нигезендә».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (Pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән

муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Советының җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин